***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА

# БИРЕМНӘРЕ

(2024-2025 нче уку елы)

**5 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 54**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Яңгырау тартык авазлардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) кайнатма
   ә) шикәр
   б) коймак
   в) гөбәдия

2. Парсыз саңгырау тартыкны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [ф]
   ә) [т]
   б) [һ]
   в) [ч]

3. Җөмләдәге [э] авазының санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Һәр эшнең дә җае бар, ботканың да мае бар*. (Мәкаль)
   а) 1
   ә) 2
   б) 3
   в) 4

4. Юлдан-юлга күчереп булмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) егет
   ә) йолдыз
   б) елга
   в) кояш

5. ***Тәмле*** сүзе күчерелмә мәгънәдә кулланылган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) тәмле күмәч
   ә) тәмле кайнатма
   б) тәмле төш
   в) тәмле аш

6. Тезмә сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) бал(сыз)
   ә) кара(бодай)

б) кием(салым)
в) бака(яфрагы)

7. Тартым белән төрләнгән исемне билгеләгез. **(2 балл)**
а) песиләр
ә) песиебез
б) песинең
в) песиләргә

8. Алмашлыкны билгеләгез. **(2 балл)**
а) алар
ә) укучылар
б) җитмеш
в) йөгерә

9. Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**
а) кечкенә
ә) кечкенәрәк
б) кеп-кечкенә
в) бәләкәй

10. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**
*Укучылар агач ботагына җимлек элделәр.*
а) укучылар
ә) агач
б) ботагына
в) җимлек

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

Татар телендә нечкә һәм _____________ сузык авазлар була. Татар телендә басым, гадәттә, сүзнең _____________ иҗегенә төшә. Капма-каршы мәгънәле сүзләр _____________ дип атала. *Сыз, сызык, сызыклы* – _____________ сүзләр. -ны/-не – _____________ килеше кушымчасы. ____________ предметның исәбен белдерәләр. Боерык фигыльләр зат-________ белән төрләнәләр. Ия __________? нәрсә? сорауларына җавап бирә.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Сүзләрне дөрес итеп урнаштырып, ике мәкаль языгыз. **(4 балл)**
*тирән, бер, диңгез, су, тамчыдан, болганчык, булмый, күренә*

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**
Моя комната небольшая. ____________________________________________
Около окна стоит письменный стол. _________________________________
На столе лежат мои учебники и тетради. ____________________________
В шкафу висит моя одежда. _________________________________________

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

КЫЕН ХӘЛ

Ишегалды бозлавык,
Бозлавыкта бер тавык.
Тукта, тукта, ни булды?
Тавык таеп егылды!

Әтәч килде ярдәмгә,
калды кыен бер хәлгә:
ярдәм итәр юлы юк.
Канаты бар, кулы юк.

(*Рөстәм Мингалим*)

2.1. Кушма сүзне күчереп языгыз. **(1 балл)**___________________________
2.2. ***Ярдәм итәр*** сүзенең синонимын языгыз. **(2 балл)** ________________
2.3. Шигырьдә кулланылган антоним сүзләрне парлап языгыз. **(2 балл)**
_________________________________________________________________
2.4. Тойгылы җөмләне күчереп языгыз. **(1 балл)**
_________________________________________________________________
3. Йорт хайваннары, кош-кортлары турында 6-8 җөмләдән торган инша языгыз. **(10 балл)**
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________